СОВЕТ ГОРОДА МАМАДЫШ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. М. Джалиля, 23/33, г. Мамадыш,
422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МАМАДЫШ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ
М.Җәлил ур., 23/33, Мамадыш ш., 422190

тел.:(85563) 3-15-90, факс 3-24-00 ; e-mail:gorsovet.mamadysh@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ**
**№ 3-23**

**КАРАР**
**«13» август, 2024 ел**

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советының 2023 елның 21 августындагы 3-15 нче карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы, «Региональ салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2024 елның 12 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законнары, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советының 2023 елның 21 августындагы «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 3-15 номерлы карарына (алаг таба –карар) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1 пунктка түбәндәге эчтәлектәге5 пунктча өстәргә:

«5) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң физик затларның 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәренең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы<br>
Мамадыш муниципаль районы<br>
Мамадыш шәһәре башлыгы<br>
вазифаларын башкаручы В.А.Захаров